ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

КАРАР
2018 елның 14 декабре

РЕШЕНИЕ
№ 267

«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең хокукый хәлен камилләштерү турында» Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 28 сентябрендәге 85 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы юстиция министры Заһидуллин Р.И. 2018 елның 01 июнендәге 10-06/8579 номерлы йөкләмәсен үтәү өчен, җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешмаларда (учреждениеләрдә) мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу максатыннан, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 28 сентябрендәге 85 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе турында Положениегә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле 6.1 бүлек өстәргә:

«6.1. Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу

«6.1.1. Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә бүлек эшчесенең шәхси кызыксынучанлыгы аның хезмәт бурычларын тиешенчә үтәвенә йогынты ясарга мөмкин һәм шул ук вакытта бүлек хезмәткәренең шәхси кызыксынуы һәм аның эшчесе булган бүлекнең законлы мәнфәгатьләре һәм хокуклары арасында каршылыклар килеп чыгарга мөмкин булган һәм бүлекнең мөлкәтенә һәм эш абруена зыян китерергә сәләтле вәзгыять аңлашыла.

6.1.2. Хезмәттәге бурычларын тиешенчә үтәүгә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган бүлектә эшләүченең шәхси кызыксынуы дигәндә, акча, кыймметләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәти хокуклар, яисә мөлкәти характердагы хезмәтләр рәвешендә яисә өченче затлар өчен керемнәрнең хезмәт бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүлек хезмәткәре тарафыннан алу мөмкинлеге

аңлашыла.

6.1.4. Учреждение хезмәткәре Учреждение җитәкчесенә вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итәргә тиеш. Учреждение директорына хәбәр итү тәртибе, хәбәрнамәләрдә булган белешмәләр исемлеге, әлеге белешмәләрне тикшерүне оештыру һәм хәбәрнамәләрне теркәү тәртибе учреждение директоры тарафыннан билгеләнә.»

3. Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - мәгариф бүлеге башлыгы Әхмәтҗанов Нияз Камил улын «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе турындагы нигезләмәне дәүләт теркәвенә алу буенча мөрәҗәгать итүче яңа редакциядә чыгыш ясарга.

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә урнаштыручы даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет председателе,
Район башлыгы Р.Г. Кәлимуллин